# Я выбираю спорт как альтернативу пагубным привычкам

Акция

Акция

Акция

Акция

Акция

# САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МБГМ «МИЧӘН УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ



Безнең мәктәп гөрләп тора
Һәркем дә хәрәкәттә.
Спорт белән дус булганга
Килә ул бәрәкәт тә.

Йөзебездән нур бөркелә,
Кулыбыздан һәр эш килә.
Бездәйләр сирәк.
Йөгерәбез, сикерәбез,
Ярышларда сыналабыз
Без спортны яратабыз,
Шәп шул без бигрәк!

Адрес: 422055
РТ Сабинский район
С. Старый Мичан
Ул.Школьная,д.10
E – mail: mishansaba
@ yandex.ru

# «Я выбираю спорт как альтернативу пагубным привычкам» акциясенә ПЛАН

| № | Эш төре | Вакыты<br>Октябрь ае | җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Велосипед ярышы | 15-10 | Мубараков Р.И. |
| 1. | Волейбол ярышы | 16 - 20 | Дума |
| 1. | Рәсемнәргә конкурс | 16 - 20 | 1-11 класс җитәкчеләре |
| 1. | Плакатларга конкурс | 16 - 20 | Ибрагимова М.Г. |
| 1. | Интернет дәрес | 18 | Ситдикова Р.Р. |
| 1. | Класслар арасында ярышлар | 16 - 20 | Мустафин Р.С.<br>Ибрагимов Р.З.<br>Мубараков Р. И. |
| 1. | Сочинениеләр язу | 16 - 20 | Миннебаева И.М.<br>Ибрагимова С.М.<br>Мустафина Ф.М. |
| 1. | Бердәм йөгерү | 21 | Шәйдуллин Р.М. |
| 1. | Түгәрәкләр эшчәнлеген тикшерү | Атна дәвамында | Ситдикова Р.Р. |
| 1. | Отчёт язу, папка туплау | 22-24 | Ситдикова Р.Р. |

15 октябрь

# Велосипед ярышы





15 октябрь көнне район күләмендә велосипедта йөрү буенча ярыш оештырылды. Мәктәпнең велосипедта йөрергә яратучы укучылары Рафиль Илһамович җитәкчелегендә ярышта катнаштылар.



Җитез һәм чыдам булырга
Без өйрәнеп үсәбез.
Ярышларда катнашабыз-
Без спортны ЯРАТАБЫЗ!



16 октябрь

# Волейбол ярышы



16 октябрьдән 7-11 класслар арасында волейбол ярышы башланды



Ярышны оештыручылар:
укучылар думасының
спорт комитеты







## Ярыш нәтиҗәләре

7-8 класс:
7-9 класс
7- 10+11 класс




17 октябрь

# Без начар гадәтләргә каршы чыгабыз


## РӘСЕМНӘР КОНКУРСЫ



11 класс укучысы Фасхетдинова Сөмбелә




8 класс укучысы Миннебаев Назиф




9 класс укучысы Хайруллин Инсаф




7 класс укучысы Харисова Гөлназ

Наркомания – ак үлем дип
Юкка гына әйтмиләр.
Кеше гомерен өзә ул,
Ник аны бетермиләр???

Без беләбез: начар гадәт
Илтми ул яхшылыкка.
Начар гадәтле кешене
Кертмәгез арагызга!

18 октябрь


# Интернет-дәрес

## Син яшәргә тиеш!

***Игътибар! Җәмгыятебез иминлегенә, планетабыз бөтенлегенә наркотиклар яный!***

Бүгенге көндә яшьләрнең 25% наркоманнар исемлегендә булуын исәкә алсак, киләчәк буыннарның да берничә тапкыр артыграк күләмдә авыруларын исәпләп чыгаруы авыр түгел.

Җир шарындагы халыклар кайчан бердәм рәвештә наркоманиягә каршы сугыш игълан итерләр икән? Планетабызны хәләкәткә китерүче әлеге чирне ничек юып төшереп булыр икән?



Яшь дустым!
Наркотиктан баш тарт!



## Наркомания кая илтә?

Наркотиклар белән танышу 11-14 яшьтә күзәтелә. Наркоман наркотиклар кабул итә башлаганнан соң 4 кенә ел яши ала.

80 % очракта наркомания дәвалап булмастай ике авыруга – гепатит –С һәм СПИД ка илтә.

Наркоманиянең төп үзенчәлеге – наркотиклар кулланудан соң психикага ясалган зарар дәвалауга бирелми. Кайбер ата – аналар балаларының наркоман икәнен белмәскә дә мөмкин. ә белгәндә инде соң була.

Наркомания куркынычы кемнәргә яный соң?

Психик авыруларга

Якын туганнарында алкоголизм. Наркомания һәм психик авырулар булганда

Яшьтәшләре белән авыр аралашучыларга

Гаиләдә низаглар еш булганда

әти - әниләре кирәгеннән артык контрольдә тотсалар яки игътибар җитмәсә акчасы күп булганда.

# Спорт түгәрәкләре

15-20 октябрь

Сәламәтлек – иң зур байлык-
Кирәк кадерен белергә.
өйдә генә утырмыйча,
Түгәрәккә йөрергә

Волейбол

Бадминтон

Татарча көрәш







Мәктәптә без күп язабыз
Кулларыбыз нык арый
Ял иттереп алу өчен
Түгәрәкләр бар ярый.

Безнең якта көчлеләр дә,
Көрәшчеләр бихисап.
Шулай булмый,Мичән ягы –
Спортка тартылган як.

Анда көрәш түгәрәген
Җитәкли Инсаф абый.
Өч авылда өч түгәрәк
Малайлар арттан калмый.

Волейбол түгәрәге җитәкчесе Мустафин Рамил Салихович
Бадминтон түгәрәге җитәкче- Ибрагимов Рамил Зөфәрович
Көрәш түгәрәге җитәкчесе – Файзрахманов Инсаф Хисаметдинович

# Шахмат түгәрәге



Яшәр өчен бәхет кирәк.
Сабырлык, әдәп, сәләт.
Дөньяң гел түгәрәк булыр,
Булсаң әгәр сау – сәламәт.

Аякларың йөгереп торса,
Күрсә күңелең күзе.
Башың бик яхшы эшләсә,
Бу – бәхетнең нәкъ үзе.

Шахмат – кызык уен,
Уйный белеп уйнасаң.
Җиңеп була, көндәшеңнән
Алданрак уйласаң.

Шахмат түгәрәге җитәкчесе- САфиуллин Ринат Исламович. Укучылар түгәрәккә бик теләп йөриләр. Һәр айны шахмат турниры үткәрәләр. Район күләмендә призлы урыннар яулыйлр. Октябрь аеның  абсолют җиңүчесен билгелиләр.

21 октябрь

# Хәрәкәттә - бәрәкәт

## Иртәнге зарядкада йөгерү



Ибрагимов Р.З. дистанцияне аңлата

Иртә торыйк,
Җитез булыйк,
Без иренмик бер дә.
1,3,3, физзарядканы
Йөгерүдән башлыйк,
әйдәгез бергә.



Зарядкага барлык укучылар
һәм укытучылар әзер







Сәламәт булырга теләсәң, ЙӨГЕР!!!









# Иртәнге зарядка

атнаның 4 көнендә

7.40 – 7.50

Сәламәт бала дибез
Кем соң ул, нинди була?
Бездә менә мондыйрак,
Таныш бул ,тыңлап кара.

Вакытында торасың,
Урыныңны җыясың,
Физзарядка ясыйсың,
Иртәнге аш ашыйсың,
Һәм мәктәпкә атлыйсың.

Ә мәктәптә гел хәрәкәт,
Хәрәкәттә - бәрәкәт.
Хәрәкәтләнеп торгач.
Барыбызга да рәхәт.

Һәркөн иртән бөтенебез
Ясыйбыз физзарядка.
Башыбыз да, кулыбыз да
Киләдер хәрәкәткә.

1-4 класслар иртәнге зарядканы коридорда үткәрә





5-11 класслар иртәнге зарядкага спортзалга җыела

20 октябрь

# Без спортны яратабыз, ярышабыз,узышабыз

5-6 класслар арасында ярыш



Командалар әзер



Мустафина Ф.М. ярышның тәртибен аңлата



Көңгерә уены



Низамова Лилия – иң җитезе



Икебезгә бер капчык



Мин җиңәчәкмен

Ярышны оештырды 5 класс җитәкчесе Мустафина Фәрдия Махияновна

# Спортны барлык начар гадәтләргә каршы куябыз

21 октябрь

8-11 класс укучыларының дума утырышы




Укучылар тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Ситдикова Равия Рафаэлевна белән
“Я выбираю спорт как альтернативу пагубным привычкам” тренингы вакытында



Дустыма киңәш бирәм



Тәмәке тартуның сәбәпләрен эзләү



Мәдәният комитеты “Игры нашего времени” проектын тормышка ашыра

Икенче Өлештә “Игры против вредных привычек” уеннарын Мәдәният Комитеты оештырды



Биз биибез



Нәтиҗә :”Я выбираю спорт как альтернативу пагубным привычкам»

# Начар гадәтләргә юл куймыйбыз - Сәламәт булу өчен тырышабыз.



Балаларның сәламәтлеге өчен мәктәптә бөтен шартлар булдырылган



Дәресләрдә физминутка ясыйбыз





Дәрестә,тәнәфестә Без гел хәрәкәттә

Без спортны сайлыйбыз





«Путь к успеху» программасы буенча
эти – әниләр белән эш



Иң көчле гер күтәрүчеләр - бездә



